# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылы торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

№ 2

**2022 елның 23 ноябре**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Әлмәт авылы территориясендә I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан тыш, Әлмәт авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Әлмәт авылында артезиан скважиналары коеларын урнаштыру, ремонтлау һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү) ;

2) Әлмәт авылында "Олы яр"чишмәсен һәм шлагбаумнарны буярга буяулар сатып алу;

3) Әлмәт авылында триммерлар һәм генератор өчен запчасть һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу;

4) Әлмәт авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту;

5) Әлмәт торак пунктында МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары, өстәмә асылмалы, тагылма җиһазлар, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);

6) Әлмәт авылында Ленин урамы, Тукай урамы, Молодежная урамы, Л. Рәхмәтуллин урамнары буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материаллар сатып алу һәм транспортлау, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) ;

7) Әлмәт авылында халык күпләп ял итә торган урыннарны һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү);

3. Әлеге карарны Әлмәт авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче — Д.Ә.Газизов